СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12.03.2026 г.Лениногорск № 6

Лениногорск муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 55 номерлы карары белән расланган муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлегенә(23.11.2023 №82 карары редакциясендә) үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтүе) һәм муниципаль контроле турында 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Төзелеш министрлыгының 2025 елның 20 маендагы 301/пр номерлы «Дәүләт торак күзәтүе һәм муниципаль торак контроле башкарганда кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычының типик индикаторларын раслау турында» боерыгына нигезләнеп, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 55 номерлы карары белән расланган муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлегенә (23.11.2023 №82 карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 һәм 7 пунктлары белән түбәндәгечә тулыландырырга:

«6. Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыручы органның, Россия Федерациясе арбитраж суды тарафыннан энергия белән тәэмин итү (сатып алу-сату, электр энергиясе (көч) белән тәэмин итү, җылылык белән тәэмин итү һәм (яки) кайнар су белән тәэмин итү, салкын су белән тәэмин итү, су чыгару, газ белән тәэмин итү (шул исәптән баллоннарда көнкүреш газы белән тәэмин итү) килешүе буенча бурычларны түләтү турында дәгъва гаризасы (дәгъва гаризалары) кабул ителүе турында мәгълүматка ия булуы, күпфатирлы йортта милекчеләргә һәм кулланучыларга тиешле төрдәге коммуналь хезмәт күрсәтүне тәэмин итү һәм күпфатирлы йортта гомуми милекне тоту вакытында кулланылган коммуналь ресурсларны сатып алу максатында, каты коммуналь калдыклар белән эш итү хезмәтләрен күрсәтү килешүе буенча, гомуми суммасы

өч йөз мең сумнан артып киткән, карар кабул ителгән көнгә кадәр уникe ай эчендә барлыкка килгән бурычлар турында мәгълүматка ия булуы.

7. Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыручы органның, Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты тарафыннан тарифлар буенча расланган куллану нормативыннан чыгып, җылылык өчен коммуналь хезмәткә түләүне өч исәп-хисап чоры рәттән исәпләү турында мәгълүматка ия булуы.».

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының экология, табигатьтән файдалану, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль
районы Башлыгы,
Совет рәисе М.Н.Гирфанов